**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОКАДЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Советская ул, 51, с.Утыз Имян ,423109

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Совет урамы, 51, Утыз Имән авылы, 423109

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

**№12** **«19» сентябрь 2019 ел**

# КАРАР

## Референдумны башлап җибәрү турында

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Яңа Кади авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

Киләсе мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

«Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 төркем инвалидлардан тыш Яңа Кади авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 550 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

1. Утыз Имән торак пунктында "Чәчәкле алан" чишмәсе территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару (хезмәтләр күрсәтү) өчен кирәкле материаллар сатып алу.
2. Утыз Имән торак пунктында һәм Кызыл Чишмә авылында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

3. Утыз Имән торак пунктында 1 һәм 4 номерлы зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (койма урнаштыру (ремонтлау), агачларны кисү, коры-сарыдан чистарту, проект-смета документлары өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.
4. Утыз Имән һәм Кызыл Чишмә авылларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары сатып алуга, хезмәтләр күрсәтүгә), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.
5. Утыз Имән авылында 4 данә күләмендә тавыш көчәйткечләр урнаштырырга һәм 3 км озынлыктагы чыбык сузарга.
6. Совет урамында 200 метрга 20-30 мм фракциясендә вак таш сатып алырга.

7. Утыз Имән авылының 1 нче һәм 2 нче скважиналарын лицензияләү өчен түләү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Яңа Кади авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Әминов М. М.